| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

27.05.2022 № 81

2022 елда «Туристлык
алдынгысы» республика
конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2024 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында туристлык базарында иң яхшы катнашучыларны һәм аның юнәлешләрен ачыклау максатларында боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән, 2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының «2020 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын үткәрү турында» 2021 елның 09 августындәге 132 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.
3. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (А.А.Кайманова) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшен оештырырга.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча рәис урынбасары Г.М.Сафинны җаваплы итеп билгеләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2022 елның 27 маендагы 81 номерлы боерыгы белән расланды

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын

үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү һәм оештыру тәртибен, шартларын, шулай ук Конкурста катнашучыларга, конкурс документларына карата таләпләр һәм аларны конкурска бирү тәртибен, конкурсны үткәрү срокларын билгели.

1.2. Конкурсның максаты – туристлык эшчәнлегендә катнашучыларның иң яхшыларын һәм юнәлешләрне ачыклау, туристлык бизнесы көчләрен берләштерү һәм Татарстан Республикасында заманча югары нәтиҗәле һәм конкурентлыкка сәләтле, Татарстан Республикасы икътисады үсешенә шактый өлеш кертүне тәэмин итә торган туристлык комплексын оештыру мәсьәләләрен хәл итүгә этәргеч бирү.

1.3. Конкурсны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) оештыра. Конкурс Конкурс комиссиясе составына кертелә торган, Конкурсны оештыручылар сыйфатында туристлык өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар белән берлектә үткәрелә.

1.4. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары белән расланган «2014-2024 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашу бушлай, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Конкурста Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән туристлык индустриясе субъектлары (кунакларны урнаштыру оешмаларын һәм күмәк чараларны, шул исәптән шифаханә-курортта дәвалау һәм ял, танып белү, эшлекле, дәвалау-савыктыру һәм башка төрле билгеләнештәге оешмаларны, шулай ук тур операторы һәм тур агентлыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны да һ.б. кертеп), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары, Татарстан Республикасының тармактагы уку йортлары, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары (газеталар, журналлар, телевидение), шулай ук 22 яшьтән 60 яшькәчә физик затлар катнаша.

2.3. Конкурста катнашу өчен номинантларны юридик һәм физик затлар тәкъдим итә. Конкурста катнашу бер яки берничә номинациядә (ихтыярга карап) гамәлгә ашырыла.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс бер этапта 2022 елның 4 октябреннән 20 декабренә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турында мәгълүмат Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – Дәүләт комитеты сайты) конкурс документларын кабул итә башлаганчы кимендә 15 календарь көне алдан урнаштырыла.

3.2. Дәүләт комитетына конкурс документларын тапшыру срогы – 2022 елның 4 октябреннән 18 ноябренә кадәр.

Конкурс документлары 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, М. Горький урамы, 19 йорт (1 нче кабинет) адресы буенча почта аша җибәрелә.

Конкурс документларының электрон версиясе Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты хезмәткәренең электрон адресына кабатлап җибәрелә: liderturizma@yandex.ru

3.3. Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән срокта тапшырылган, эчтәлеге һәм рәсмиләштерелүе әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс документлары кабул ителә.

3.4. Конкурста катнашу өчен Дәүләт комитетына тутырылган анкета-гариза (формалар кушымтада бирелә), номинацияләр нигезендә әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктчасында күрсәтелгән документлар, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (киңәш ителә торган форма әлеге Нигезләмәнең 7 нче кушымтасында китерелгән), персональ мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (киңәш ителә торган форма әлеге Нигезләмәнең 8 нче кушымтасында китерелгән) тапшырыла;

3.5. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Ел ачышы – 2022».

2) «Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә ярдәм итү» – түбәндәге бүлекләр буенча:

«Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә – 2022»;

«Туристлык белеме өлкәсендә – 2022»;

«Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә – 2022» – «Татарстан Республикасының читтән килү һәм эчке туристлыкны популярлаштыруга багышланган иң яхшы материал».

3) «2022 ел персонасы – туристлык үсешенә шәхси өлеш керткән өчен».

4) «Татарстан Республикасы буенча 2022 елның иң яхшы маршруты».

5) «2022 елда Татарстан Республикасы балалар туристлыгының иң яхшы тур операторы».

6) «Татарстан Республикасының 2022 елгы иң яхшы тур операторы».

7) «Туристлык буенча 2022 елда иң яхшы волонтер».

8) «2022 елда иң яхшы экскурсия уздыручы».

9) «2022 елгы туристлык сувенирлары».

10) «Татарстан Республикасының 2022 елгы иң яхшы шифаханәсе».

3.6. «Ел ачышы – 2022» номинациясендә катнашу өчен Конкурска, 2022 елда туристлык өлкәсендә тормышка ашырылган проектны теркәп, анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы) тапшырыла.

«Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә ярдәм итү – 2022» номинациясендә Татарстан Республикасының туристлык үсешенә өлеш керткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары анкетада китерелгән махсус күрсәткечләр буенча бәяләнә (әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы). Анкетага өстәмә рәвештә районның туристлык паспорты, муниципаль районда туристлык үсеше буенча проект/программа һәм аны гамәлгә ашыру дәрәҗәсе теркәлә, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтына сылтама күрсәтелә.

«Туристлык белеме өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә ярдәм итү – 2022» номинациясендә Татарстан Республикасының тармактагы уку йортлары анкетада китерелгән махсус күрсәткечләр буенча бәяләнә (әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы). Анкетага өстәмә рәвештә уку йортының турфирмалар, кунакханәләр белән үзара бәйләнешен, Татарстан Республикасында туристлык үсеше буенча 2021 елда тормышка ашырылган проектларны, уку йортының туристлык эшчәнлегендә алга этәрү ысулларын күрсәтеп, документлар теркәлә.

«Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә Татарстан Республикасының туристлык эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү – 2022» номинациясендә Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чаралары (газеталар, журналлар, радио, телевидение) бәяләнә. Конкурска, 2022 елда басылып чыккан материалларны теркәп, анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы) тапшырыла.

«2022 ел персонасы – туристлык үсешенә шәхси өлеш керткән өчен» номинациясендә катнашу өчен Конкурска физик заттан яки оешма исеменнән төзелгән анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасы) тапшырыла.

«Татарстан Республикасы буенча 2022 елның иң яхшы маршруты», «2022 елда Татарстан Республикасы балалар туристлыгының иң яхшы тур операторы», «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы тур операторы», «Туристлык буенча 2022 елда иң яхшы волонтер», «2022 елда иң яхшы экскурсия уздыручы», «2022 елда туристлык сувенирлары», «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы шифаханәсе» номинацияләре буенча Конкурс аны оештыруда ярдәм күрсәтүче затлар тарафыннан үткәрелә.

Конкурсны оештыруда ярдәм итүче затлар Конкурс турында нигезләмә, Конкурсны үткәрү тәртибен, шартларын раслый һәм оештыра, Конкурста катнашучыларга, Конкурс документларына карата таләпләр һәм аларны Конкурска тапшыру тәртибен, Конкурсны үткәрү срокларын билгели.

«Татарстан Республикасы буенча 2022 елның иң яхшы маршруты», «2022 елда Татарстан Республикасы балалар туристлыгының иң яхшы тур операторы» һәм «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы тур операторы» номинацияләре буенча конкурсны оештыруда ярдәм итүче – Татарстан Республикасы Туристлык агентлыклары ассоциациясе.

«Туристлык буенча 2022 елда иң яхшы волонтер» номинациясе буенча Конкурсны оештыруда ярдәм итүче зат булып «Татарстан Республикасының Туристлык волонтерлары ассамблеясы» автоном коммерциясез оешмасы тора.

«2022 елда иң яхшы экскурсия уздыручы» номинациясе буенча Конкурсны оештыруда ярдәм итүче – «Татарстанның экскурсия уздыручылар гильдиясе» ассоциациясе.

«2022 елгы туристлык сувениры» номинациясе буенча Конкурсны оештыруда ярдәм итүчеләр – «Татарстан Республикасы Халык сәнгать кәсепчелеген һәм һөнәрчелеген үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре палатасы» коммерциясез партнерлыгы.

«Татарстан Республикасының 2022 елгы иң яхшы шифаханәсе» номинациясе буенча Конкурсны оештыруда ярдәм итүче булып «Татарстан шифаханәләре» шифаханә-курорт учреждениеләре ассоциациясе тора.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4, 3.6 пунктларында күрсәтелгән кирәкле документлар булмаганда, эш каралмый. Мөрәҗәгать итүчегә конкурс эшен конкурста катнашуга гаризада күрсәтелгән электрон почтага җибәрүдән баш тарту турында мондый карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә хәбәр ителә. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән срокта җитешсезлекләрне бетергәннән соң, кабат гариза бирә ала.

3.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән гаризалар бирү өчен билгеләнгән срокта җитешсезлекләрне бетергәннән соң, гариза бирүчеләр конкурска кабат гариза бирә алалар.

3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән датадан соң тапшырылган Конкурс документлары каралмый һәм конкурста катнашуга рөхсәт ителми.

3.10. Конкурска җибәрелгән барлык материаллар кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Конкурс комиссиясе төзү һәм аның эшчәнлек тәртибе

4.1. Алынган Конкурс документларын бәяләү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссиянең персональ составы Дәүләт комитеты боерыгы белән, Комиссиянең рәисе җитәкчелегендә, рәис урынбасары һәм җаваплы секретарьны да кертеп, республика башкарма хакимият органнары, иҗтимагый оешмалар һәм Татарстан Республикасының туристлык өлкәсендәге оешмалар вәкилләреннән 16 кешелек составта раслана.

4.3. Комиссия эшенә рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда, вазыйфалар аның урынбасарына йөкләнә. Комиссия әгъзалары булып Конкурс нәтиҗәсендә шәхсән мәнфәгатьле булган затлар тора алмый.

4.4. Комиссия эше утырышта гамәлгә ашырыла. Утырыш, әгәр барлык әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы була. Комиссиянең җаваплы секретаре тавыш бирергә хокуклы түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

әлеге Нигезләмәнең 3.1-3.4 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, материалларны кабул итә һәм терки һәм аларны саклый;

комиссия утырышын оештыра, документлар әзерли һәм беркетмә төзи.

4.6. Комиссия карары Комиссия утырышы уздырылган көнне беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче зат, җаваплы секретарь һәм комиссия әгъзалары кул куя.

## 5. Конкурс аша сайлап алу тәртибе

5.1. Конкурста җиңүчеләр комиссия утырышында билгеләнә.

5.2. Конкурсның һәр номинациясендә (һәр бүлектә берәр) бер җиңүче билгеләнә. Җиңүчеләр дәүләт комитеты исеменнән махсус дипломнар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнә.

5.3. «Татарстан Республикасының туристлык базарын үстерүгә ярдәм итү " номинацияләрендә җиңүчеләр-бүлекләр буенча:

"Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә-2022»;

"Туризм өлкәсендә-2022»;

"Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә-2022» – «Татарстан Республикасының керү һәм эчке туризмын популярлаштыруга багышланган Иң яхшы материал" конкурс материалларын бәяләү критерийлары нигезендә билгеләнә (әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасы).

5.4. Комиссия тәкъдим ителгән конкурс материалларын бәяли. Һәр критерий буенча баллар саны биш баллы шкала буенча билгеләнә (1дән 5кә кадәр). Гариза бирелгән номинациядә иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип танылa. Иң күп балл җыйган берничә катнашучы булса, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә. Комиссия утырышында рәислек итүче тавышларның тигезлеге булганда, хәлиткеч тавыш санала.

5.5. «Ел ачышы – 2022», «2022 ел персоналы – туризм үсешенә шәхси өлеш өчен» номинацияләрендә җиңүчеләр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гади тавыш белән билгеләнә. Комиссия утырышында рәислек итүче тавышларның тигезлеге булганда, хәлиткеч тавыш санала.

5.6. «Татарстан Республикасы буенча 2022 елның иң яхшы маршруты», «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы балалар туризмы туроператоры», «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы туроператоры», «2022 елда иң яхшы туристик волонтер», «2022 елда иң яхшы экскурсовод», «2022 елда Туристлык сувениры», «2022 елда Татарстан Республикасының иң яхшы санаторие» номинацияләрендә җиңүчеләр үзләре үткәргән конкурс нәтиҗәләре буенча конкурсны оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

5.7. Номинацияләрнең берсенә бер генә гариза да бирелмәгән, бер генә гариза да конкурс шартларына туры килми, номинациядә җиңүче билгеләнмәгән, әлеге номинациядә Конкурс үтмәгән дип таныла.

5.8. Конкурс нәтиҗәләре Дәүләт комитеты боерыгы белән комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә өч көнлек срокта раслана, ул кул куелганнан соң эш көннәрендә исәпләнә.

5.9. Конкурс нәтиҗәләре Дәүләт комитеты тарафыннан оештырыла торган 2022 елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшыру тантанасында игълан ителә.

Конкурс нәтиҗәләре турында игълан дәүләт комитеты сайтында конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшыру тантанасы уздырылган көнне басыла.

5.10. Конкурсны оештыручы үзе артыннан хокук калдыра:

тәкъдим ителгән конкурс материалларын Үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга;

Материалларны телевидение һәм радиокомпанияләр эфирында урнаштырырга.

5.11. Катнашучылар әлеге Нигезләмәнең барлык шартлары белән тулы һәм берсүзсез килешүләрен үзләренең конкурс документларын конкурска җибәрү факты белән раслыйлар.

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: *ЕЛ АЧЫШЫ – 2022*

1. Тутыру датасы ____________________________
2. Оешманың тулы атамасы ____________________________________________
_____________________________________________________________________________
3. Адрес _______________________________________________________________________
4. Лицензия ____________________________________________________________________
5. Директорның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
_______________________________________________________________________________
6. Элемтә өчен телефон _________ факс ______________ E-mail _____________________
7. Web-сайт ____________________________________________________________________
8. Проектның характеристикасы (максаты, актуальлеге, яңалыгы)

9. Татарстан Республикасында туристлыкны үстерү өчен әһәмияте

10. Бүләкләр, проект турында мәкаләләр, кайтавазлар (материалларны теркәп).

11. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре

Искәрмә: Калын сызыклы урыннарны Конкурс комиссиясе тутыра.

2022 елда «Туристлык алдынгысы»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 2 нче
кушымта

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә
*ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022»;

| | |
|---|---|
| 1. Тутыру датасы ____________________________<br>2. Оешманың тулы атамасы ____________________________________________<br>3. Адрес ____________________________________________________________________________________<br>4. Нигез салыну датасы ___________________________________________________________________________<br>5. Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>________________________________________________________________________________<br>6. Элемтә өчен телефон _________ факс ______________ E-mail ____________________________________<br>7. Web-сайт ______________________________________________________________________________ | |
| 8. Районның туристлык паспортының тулылыгы (эчтәлеге, структурасы, мәгълүматлылыгы, актуальлеге) | Тасвирлама |
| 9. Web-сайтның тулылыгы – (мәгълүматлылык, актуальлек, куллану уңайлылыгы, тышкы кыяфәте, дизайны, структурасы һәм навигация, сайтның мобиль версиясе булу) (сылтама күрсәтергә) | |
| 10. Муниципаль районда туристлыкны үстерү проекты / программасы һәм аны тормышка ашыру дәрәҗәсе (эчтәлеге, структурасы, мәгълүматлылыгы, актуальлеге, уникальлеге, билгеләнгән максатларга туры килүе) | |
| 11. Муниципаль берәмлекне туристлык базарында таныту рәвешләре (баннер реклама һәм хәбәр тарату, матбугат өчен мәгълүматлар, партнерлык программалары, почта элемтәсе, мәгълүмат бирә торган туристлык үзәге булу) (санап чыгарга) | |
| Конкурс комиссиясенә презентация продукциясе, шул исәптән булган барлык чит телләрдә дә, тәкъдим ителә | |
| 12. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре | |

Искәрмә: Калын сызыклы урыннарны Конкурс комиссиясе тутыра.

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Туристлык белеме өлкәсендә
*ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022»

| | |
|---|---|
| 1. Тутыру датасы ____________________________<br>2. Оешманың тулы атамасы ___________________________________________<br>3. Адрес ___________________________________________________________<br>4. Нигез салыну датасы ____________________________________________<br>5. Лицензия _________________________________________________________<br>6. Аккредитация ____________________________________________________<br>7. Сертификат ______________________________________________________<br>8. Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>___________________________________________________________________<br>9. Элемтә өчен телефон _________ факс ______________ E-mail _________________________<br>10. Web-сайт _______________________________________________________ | |
| 11. Турфирмалар белән хезмәттәшлек (программаларны бергәләп эшләү, хәзерге һәм киләчәк өчен ихтыяҗларны мониторинглау, кадрларга ихтыяҗ булуын күзәтү, өйрәнү тәҗрибәсе, стажировкалар, эшкә урнашу мөмкинлеге) | |
| 12. Кунакханәләр белән хезмәттәшлек (программаларны бергәләп эшләү, хәзерге һәм киләчәк өчен ихтыяҗларны мониторинглау, кадрларга ихтыяҗ булуын күзәтү, өйрәнү тәҗрибәсе, стажировкалар, эшкә урнашу мөмкинлеге) | |
| 13. Татарстан Республикасы Туриситлык буенча дәүләт комитетының туристлык индустриясе өлкәсендә кадрлар әзерләүдә ярдәм күрсәтү методик советы чараларында катнашу ешлыгы (күпме, ниндиләрдә икәнен күрсәтергә) | |
| 14. 2022 елда Татарстан Республикасында туристлык үсеше буенча гамәлгә ашырылган проектлар (эчтәлеге, структурасы, мәгълүматлылыгы, актуальлеге, уникальлеге, билгеләнгән максатларга туры килүе) | |
| 15. Уку йортын туристлык эшчәнлеге өлкәсендә алга таба күрсәтү (ачык ишекләр көне уздыру, реклама һәм мәгълүмат тарату, партнерлык программалары, почта аша мәгълүматлар җибәрү) | |
| 16. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре | |

Искәрмә: Калын сызыклы урыннарны Конкурс комиссиясе тутыра.

2022 елда «Туристлык
алдынгысы» республика
конкурсын үткәрү турындагы
нигезләмәгә 4 нче кушымта

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
*ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022»

| |
|---|
| 1. Тутыру датасы ________________________________________________<br>2. Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>____________________________________________________________________<br>3. Эш урыны, вазыйфасы __________________________________________<br>4. Мәкаләнең исеме (баш исеме) ____________________________________<br>5.ММЧ атамасы_______________________________________________<br>6. Басылып чыгу датасы _________________________________________<br>7. Мәкаләгә сылтама _____________________________________________<br>8. Элемтә өчен телефон ___________________ E-mail ________________________<br><br>9. Анкета-гаризага кушымталар:<br>- басма ММЧ мәкаләләр – мәкаләнең PDF форматындагы скан рәвеше, редакциядән материалны бастырып чыгару датасын раслый торган белешмә, авторның (авторларның) массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе тарафыннан таныкланган исеме;<br>- TV өчен видеосюжет – видеосюжетка сылтама;<br>- Интернет челтәрендәге мәкалә – битләрнең скриншотлары. |
| 10. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре |

Искәрмә: Калын сызыклы урыннарны Конкурс комиссиясе тутыра.

2022 елда «Туристлык алдынгысы»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 5 нче
кушымта

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «*2022 ел персонасы – туристлык үсешенә керткән шәхси өлеше өчен*»

1. Тутыру датасы ______________________________________________________________

2. Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
________________________________________________________________________

3. Туган көне, ае, елы ____________________________________________________

4. Эш урыны һәм вазыйфасы (булган очракта) _________________________________

5. Туристлык өлкәсендәге эш стажы ________________________________________

6. Һөнәрендәге шәхси казанышлары (туристлык үсешенә шәхси өлешне тасвирлау (нәрсә эшләнгән, нәрсәгә юнәлдерелгән), аның масштабы (территориаль колачланышы), нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре):

7. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре

Искәрмә: Калын сызыклы урыннарны Конкурс комиссиясе тутыра.

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 6 нчы кушымта

Конкурс материалларын бәяләү критерийлары

| Критерий исеме | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| *Муниципаль районның туристик паспортының тулылыгы (эчтәлек, структурасы, мәгълүматлылык, актуальлек) | | | | | |
| *Муниципаль район Web-сайтының тулылыгы (Сайтның мобиль версиясе булу, актуальлеге, куллану уңайлылыгы, тышкы кыяфәте, дизайн, структурасы һәм навигациясе) | | | | | |
| *Туризмны үстерү программасы, перспективалы проектларны гамәлгә ашыру (эчтәлек, структуралаштыру, мәгълүматлылык, актуальлек, уникальлек, билгеләнгән максатларга туры килү) | | | | | |
| *Муниципаль районның туристлык базарында алга таба мавыктыру рәвешләре (баннерлы реклама һәм рассылка, пресс-релизлар, партнерлык программалары, почта җибәрү, мәгълүмати туристлык үзәге булу) | | | | | |
| **Туристик фирмалар белән хезмәттәшлек формалары (программаларны бергәләп эшләү, агымдагы һәм перспективалы ихтыяҗларны мониторинглау, кадрларга ихтыяҗ мониторингы, укыту практикасы, стажировка, эшкә урнашу мөмкинлеге) | | | | | |
| **Кунакханәләр белән хезмәттәшлек формалары (программаларны бергәләп эшләү, агымдагы һәм перспективалы ихтыяҗларга мониторинг, кадрларга ихтыяҗ мониторингы, укыту практикасы, стажировка, эшкә урнашу мөмкинлеге) | | | | | |
| **Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитетының туристлык өлкәсендә кадрлар әзерләүдә ярдәм күрсәтү буенча методик советы чараларында катнашу, туристлык юнәлешендәге чараларда катнашу, һөнәри осталык чемпионатларында катнашу | | | | | |
| **Татарстан Республикасында 2022 елда гамәлгә ашырылган туризмны үстерү буенча проектлар (эчтәлек, структуралашу, мәгълүматлылык, актуальлек, уникальлек, билгеләнгән максатларга туры килү) | | | | | |
| **Уку йортын туристлык базарында таныту (ачык ишекләр көне үткәрү, реклама һәм рассылка, партнерлык программалары, почта җибәрү) | | | | | |
| *** Сайланган тема буенча иң информатив һәм эчтәлекле материал, актуаль һәм көн кадагындагы, туристлык индустриясе проблемасын яктыртучы | | | | | |
| *** Бәян ителгән телнең һәм стильнең төгәллеге һәм дөреслеге (стиль, изложение теле һәм материалның дөреслеге, мәгълүматлылык) | | | | | |

* Муниципаль туристлык сәясәте өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022 номинациясендә бәяләнә (2 нче кушымтадагы анкета-гариза нигезендә)

** Туристлык белеме өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022 номинациясендә бәяләнә (3 нче кушымтадагы анкета-гариза нигезендә)

*** Массакүләм мәгълүмат коммуникацияләре өлкәсендә *ТУРИСТЛЫК БАЗАРЫН ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ* – 2022 номинациясендә бәяләнә (4 нче кушымтадагы анкета-гариза нигезендә)

2022 елда «Туристлык алдынгысы»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 7 нче
кушымта

Киңәш ителә торган форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә
ризалык

Мин, ______________________________________________________________________,
(Фамилия, исем, ата исем (соңгысы – булган очракта))
«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына, 2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашу максатларында, шулай ук «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына күрсәтелгән чарада катнашу өчен үзем тапшырган белешмәләрне автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан башка гына да, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык бу белешмәләрне үз эченә алган тиешле мәгълүматларны яки документларны саклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чор беткәнчегә кадәр бирелә.

_________________ ______________________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата

2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 8 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
________________________________________________________________,
(почта адресы)
________________________________________________________________
(электрон почта адресы, телефон номеры)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына (алга таба – оператор) (ОГРН 1141690023364, ОКТМО 92701000001, ОКПО 48694992), Юридик адресы: 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 19 йорт, 2022 елда «Туристлык алдынгысы» республика конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыруга, бирүгә) ризалык бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге

| Тәртип саны | Шәхси мәгълүматлар | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | | | |
| 1. | Фамилия | | |
| 2. | Исем | | |
| 3. | Ата исеме (булган очракта) | | |
| 4. | Туган ел, ай, дата һәм туу урыны | | |
| 5. | Адрес | | |
| 6. | Уку/эш урыны | | |
| 7. | Вазыйфа | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган шәхси мәгълүматларның категорияләре һәм исемлеге

| Тәртип саны | Шәхси мәгълүматлар | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Шәхси мәгълүмат категорияләре] | | |

1

| | [Персональ мәгълүматлар исемлеге] | |
|---|---|---|

Искәрмә. Әлеге юл шәхси мәгълүматлар субъектының ихтыяры буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүче оператор ягыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар затларның чикләнмәгән яки чикләнгән даирәсенә шәхси мәгълүматларны тарату һәм (яки) бирү буенча оператор башкара торган гамәлләрне чикләү яки тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә рәвештә шәхси мәгълүматларны эшкәртә торган оператор тарафыннан алынган шәхси мәгълүматларның бары тик аның катгый билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән эчке челтәре аша гына яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла алуы яки алынган шәхси мәгълүматларның тапшырылмау шартлары күрсәтелә ала.

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары оператор тарафыннан затларның чикләнмәгән даирәсенә тапшырылачак һәм алар белән башка төрле гамәлләр кылыначак мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: https://tourism.tatarstan.ru/.
Әлеге ризалык ____________________________________________________________гамәлдә була.
(ризалыкның конкрет гамәлдә булу вакытын күрсәтергә)

Шәхси мәгълүматлар субъекты, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алырга хокуклы.

Персональ мәгълүматлар субъекты тарафыннан үзе биргән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы кире алынган очракта, оператор аларны эшкәртүдән туктарга яисә мондый эшкәртүнең туктатылуын тәэмин итәргә тиеш (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса) һәм, персональ мәгълүматларны эшкәртү максатында персональ мәгълүматларны саклау таләп ителмәгән очракта, аларны кире алу турында гариза алынган датадан башлап утыз көннән артмаган чорда юкка чыгарырга яки юкка чыгарылуын тәэмин итәргә тиеш (әгәр әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса). Күрсәтелгән чорда персональ мәгълүматларны юкка чыгару мөмкинлеге булмаса, оператор мондый персональ белешмәләрне блокка куя яки блокка куелуын тәэмин итә (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса) һәм алты айдан артмаган чорда персональ мәгълүматларның юкка чыгарылуын тәэмин итә.

__________________ (имза)

____________________________________________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата